| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Исполнительный комитет**<br>**Старомензелябашского сельского**<br>**поселения Сармановского**<br>**муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районы**<br>**Иске Минзәләбаш авыл җирлеге**<br>**башкарма комитеты** |

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**12 апрель 2021 ел** **№ 7**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлауны үткәрү тәртибен (1 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе А.Н.Габдрахманов

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
башкарма комитетының 2021
елның 12 апрелендәге 7 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе.

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү өчен эшләнде һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә Анализ ясау гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшнең сыйфатын күтәрү, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында үткәрелә.

3. Тиешле чорда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ гражданнарның барлык мөрәҗәгатьләре, шул исәптән язма рәвештә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү аша җибәрелгән электрон документ рәвешендә, шулай ук вәкаләтле затлар тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча башкарыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ел саен башкарыла.

5. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү нәтиҗәләре буенча хисап чорыннан соң килгән айның 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхси күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат (булган очракта) булырга тиеш.

7. Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә тиешле вакыт эчендә анализ узган елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре ел саен аналитик белешмәнең Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә «Авыл җирлекләре» бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштырылуын тәэмин итә.